**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ЯҢА АЛЕКСАНДРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**III ЧАКЫРЫЛЫШ**

**КЫРЫК ДҮРТЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 1**

Яңа Александровка авылы «20» май 2019 ел

**Татарстан Республикасы Бөгелмә**
**муниципаль районы «Яңа Александровка**
**авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә**
**ачык тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар)**
**оештыру һәм үткәрү тәртибе турында»**
**Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның**
**14 февралендәге Яңа Александровка авыл җирлеге**
**Советының XXXXI сессиясенең**
**№2 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп

**Яңа Александровка авыл җирлеге Советы**

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 14 февралендәге Яңа Александровка авыл җирлеге Советының XXXXI сессиясенең №2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. 4 бүлектә:

*- 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:*

«4. Ачык тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районының Яңа Александровка авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районының «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы («Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча үткәрелә.

Яңа Александровка авыл җирлеге советы яки халык инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар Яңа Александровка авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгы инициативасы буенча үткәрелүчесе («Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе) – «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан.».

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**«Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы** **Д.К.Меһдиев**